Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIII-2**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 21 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүен һәм 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын тәгаенләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 21 ноябрендәге
XXIII-2 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районын шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары (алга таба - шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары) муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешнең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгели, алар муниципаль район, мәгариф, сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спорт, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, каты коммуналь калдыкларны урнаштыру, муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле рәвештә җирлекләрнең электр һәм газ белән тәэмин итү, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өлкәләренә кагыла; муниципаль район халкы өчен муниципаль районның башка җирле әһәмияттәге объектлары һәм мондый объектларның муниципаль район халкы өчен максималь рөхсәт ителгән территориаль дәрәҗәсендәге исәп-хисап күрсәткечләре.

1.3. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:

1) Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның социаль-демографик составы һәм тыгызлыгы (алга таба-муниципаль берәмлек);

2) муниципаль берәмлекне комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары;

3)Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәре.

1.4. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) төп өлешне (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 маддәсендәге 3 өлешендә һәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктында каралган муниципаль берәмлек халкының объектлар белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм муниципаль берәмлек халкы өчен мондый объектларның территориаль файдалана алу

мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре);

2) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларының төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен нигезләү материаллары;

3) шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларының төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе.

1.5. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган үзгәрешләр кертү мөнәсәбәтләренә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нормалары, Россия Федерациясенең башка федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган башка норматив хокукый актлары кулланыла.

## II. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибе

2.1. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү турындагы карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә һәм муниципаль хокукый акт рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.2. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

- шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларында чагылыш табарга тиешле исәп-хисап күрсәткечләре исемлеге;

-шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектларын эшләү срокларына күрсәтмәләр;

- кызыксынган затлар тарафыннан шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләүгә кагылышлы тәкъдимнәр бирү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматлар;

-шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү эшләрен оештыруның финанс шартлары һәм башка мәсьәләләре.

2.3. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан йә товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.4. Вәкаләтле орган:

-шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын эшләү эшләрен оештыра;

-шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләүгә кагылышлы кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен җыюны тәэмин итә;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау яисә аларга үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерли.

2.5. Вәкаләтле орган шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм күрсәтелгән нормативларны кабул итүдә кызыксынучы оешмалар, дәүләт күзәтчелеге органнары (алга таба - кызыксынучы органнар) белән килештерүне гамәлгә ашыра.

Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын килештерү срогы кызыксынган органнар тарафыннан шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проекты аларга кергән көннән алып утыз календарь көн тәшкил итә.

Вәкаләтле органга билгеләнгән вакытта шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектына бәяләмәләр кертелмәгән очракта, әлеге проект килештерелгән дип санала.

2.6. Вәкаләтле орган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын урнаштыруны һәм аларны раслау алдыннан кимендә ике ай кала муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны тәэмин итә.

2.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән срок тәмамлангач, вәкаләтле орган 5 (биш) календарь көн эчендә, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын эшләп бетерә һәм аны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшыра. Кергән тәкъдимнәр турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм мондый тәкъдимнәр белән килештерүнең (риза булмауның) мотивлаштырылган нигезләнүен күрсәтү шәһәр төзелешен проектлауның эшләнеп беткән җирле нормативлары проектына мәҗбүри кушымта булып тора.

2.8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын 3 (өч) календарь көн дәвамында тәкъдим иткәннән соң, раслау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын җибәрү турында карар кабул итә.

2.9. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы тарафыннан раслана.

2.10. Региональ әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системага салуны тәэмин итү максатларында вәкаләтле орган шәһәр төзелешен проектлауның яисә аларга кертелгән үзгәрешләрнең җирле нормативларын раслаганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына аларны раслау турындагы акт күчермәсен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 12 мартындагы 149 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрына кертү өчен Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибенең 4 пункты нигезендә мәгълүматларны тапшыра. Документлар электрон рәвештә һәм кәгазь йөрткечтә тапшырыла.

2.11. Вәкаләтле орган территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында шәһәр төзелешен проектлауның расланган җирле нормативларын күрсәтелгән нормативлар расланган көннән алып биш көннән артмаган срокта урнаштыруны тәэмин итә.

## III. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү

Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.